**ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫН ХӘЛ ИТҮ**
**2024 елда гражданнарның үзара салымын кертү турында**
**Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы**
**Яңа Спас авыл җирлегенең Яңа Спас торак пунктында**

2023 елның 18 ноябре № 1

«Россия Федерациясендә жирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында жирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Яңа Спас авыл җирлегендә халык җыены, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Яңа Спас авыл җирлегендә

**КАРАР ИТТЕ:**

1. Яңа Спас авыл җирлеге Яңа Спас торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 2024 елда 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертергә, шул исәптән көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан, I төркем инвалидларыннан, ялгыз өлкән яшьтәге кешедән, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизацияләү буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнардан тыш.

2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү:

- Яңа Спас торак пунктында су белән тәэмин итү челтәрләрен ремонтлау.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Яңа Спас авыл җирлегенең мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән игълан итәргә, Зәй муниципаль районының рәсми сайтында «авыл җирлекләре» бүлегендә бастырып чыгарырга, «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» урнаштырырга (PRAVO.TATARSTAN.RU) 7 көн дәвамында (Яңа Спас авыл жирлеге Уставының 69 п.5 статьясы) кабул ителгән көннән.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Яңа Спас авыл жирлеге башлыгы Н.В.Танчук